ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 август 2023ел № 6957

Башкарма комитетның 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2018 елның 23 гыйнварындагы 251 номерлы, 2021 елның 26 мартындагы 2090 номерлы, 2021 елның 23 июлендәге 4940 номерлы, 2022 елның 29 апрелендәге 2274 номерлы карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәгә, 4 нче кушымтаның 3 пунктындагы алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Кп – сезонлы стационар булмаган сәүдә объектлары һәм җәмәгать туклануы объектлары (шул исәптән стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы) өчен кулланыла торган коэффициент – 80, консервация чорына стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы стационар булмаган җәмәгать туклануы объектлары өчен – 0, 2023 елның 1 маеннан 2024 елның 30 апреленә кадәр урнаштыру чорына стационар җәмәгать туклануы объектлары карамагындагы сезонлы стационар булмаган җәмәгать туклануы объектлары өчен – 0.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов